| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУВАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ КУАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның 5 сентябре Иске Куак №8

Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затларның исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәр прокуратурасының 2022 елның 10 августындагы 02-01-25/140-22-20920049 номерлы мәгълүматын караганнан соң, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

табиб амбулаториясе территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парк, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2. Хуҗасыз хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Сушкова Ирина Николаевнаны билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова